

21 сентябрь конне Ләмберә авылынын «Алмаз» мәдәният сараенда «Авылым тавышлары» тобәкара татар жыры фестиваль-конкурсы узды. Гаилә елына багышланган быелгы чарада Мордовия һәм Татарстаннан гына түгел, Пенза, Саратов олкәләреннән, Башкортостан Республикасы (барлыгы 40 якын гариза бирелгән) башкаручылары катнашты.

Фестивальнен топ максаты - татар халкынын фольклорына һәм милли жыр традицияләренә нигезләнгән татар жырларын популярлаштыру. Быел ул РФ Президенты Владимир Путин игълан иткән «Гаилә елы» эгидасы астында узды. «Авылым тавышлары»нын тантаналы ачышында катнашучыларны һәм тамашачыларны Мордовия Мәдәният, милли




сәясәт һәм архив эше министрлыгы исеменнән министр урынбасары Альберт Сявкаев, Ләмберә районы башлыгы Юрий Голов, Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары Разил Зиннәтуллин Жыр бәйрәме белән котладылар.
Һәр елдагыча фестиваль-конкурснын топ иганәчесе - Ләмберә районы «Юлдаш» крестьян-фермер хужалыгы житәкчесе Рафик Фетхуллов. Рафик Айяс улы конкурс

лауреатларынын һәрберсенә шәхси бvләкләр дә тапшырды.



Гала-концерт программасында заманча һәм борынгы татар жырлары, биюләр, эстрада жырлары да бар иде. Фестивальдә катнашучылар арасында торле яшьтәге башкаручы жыр коллективлары чыгыш ясады, vзләре генә дә бик матур жырладылар, биеделәр.
Чара залында махсус хәрби операциядә катнашучыларнын гаиләләре, кадерле туганнары һәм якыннары да булды. Аларга коч һәм сабырлык теләп барыбыз да сезнен улларыгыз, ирләрегез һәм әтиләрегез бе-лән горурланабыз, алар инде безнен һәр-беребез очен чын геройлар булды, дигән сvзләрне чараны алып баручылар янгыратты. Мәхәббәтегез, гаилә-гезнен коче аларны сугыш кырларында сакласын һәм һәрберсе ойләренә жинv белән кайтсын, дигән теләкләрне дә ишеттерделәр.
Ярыш булгач, ярышалар инде. Берсеннән-берсе матур жырлар,берсеннән-берсе матур тавышлар ишеттек бу конкурс барышында. Кvнелләрне тибрәндерерлек, юандырырлык иттереп жырладылар. Ярыш каты булды. Конкурс нәтижәләре остендә компетентлы, профессиональ жюри эшләде, әмма жинvчеләрне билгеләv жинел булмагандыр.
Нәти-жәләр тvбәндә.




ДИПЛОМ
ДИПЛОМ








БГ